ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06 сентябрь 2018 г. № 4987

Җир участогын арендалау килешүенә үзгәрешләр кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2015 елның 8 июнендәге 3506 нчы карары белән (Башкарма комитетның 2016 елның 29 июнендәге 3352 нче карары редакциясендә) расланган җир участогын арендалау килешүенә үзгәрешләр кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктта:

- бишенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 218-ФЗ санлы Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 20.07.2015, №29, ст. 4344);»;

- алтынчы абзацтагы «(08.05.2009 редакциясендә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

- сигезенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 221-ФЗ санлы Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 30.07.2007, №31, ст. 4017);»;

- ундүртенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары (алга таба – Муниципаль хезмәтләр исемлеге);»;

- уналтынчы абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитетның 2017 елның 28 декабрендәге 1210-р санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе турында нигезнамә (алга таба – Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе турында нигезнамә);»;

2) 2.1. пункттагы «Башкарма комитетның 2393 нче карары» сүзләрен «Муниципаль хезмәтләр исемлеге» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2.3 пункттагы «РФ Җир кодексының 39.8 маддәсенең 1 пункты» сүзләрен «РФ Җир кодексының 39.8 маддәсе» сүзләренә алмаштырырга;

4) 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | 1) Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә;<br>2) Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә;<br>3) Күчемсез милек объекты (ҖУ) турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;<br>4) Җир участогында урнашкан күчемсез милек объектларының төп характеристикалары һәм аларга теркәлгән хокуклар турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә. | 210-ФЗ санлы Федераль законның 7.1 маддәсе<br>218-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсе<br>221-ФЗ санлы Федераль законның 1 маддәсе |

5) 2.7 пункттагы «Эш регламентының 3 бүлеге» сүзләрен «Эш регламенты» сүзләренә алмаштырырга;

6) 2.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросын теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә.<br>Электрон рәвештә ял (бәйрәм) көнендә кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |

7) 3.3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитет Җитәкчесе гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгына җибәрә.

Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы гаризаны һәм

документларны карап тикшерә һәм җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең җиргә кагылышлы аренда мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлеге башлыгына (алга таба – җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге башлыгы) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.»;

8) 3.4.1 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турында запросларны формалаштыру һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон рәвештә җибәрү.»;

9) 3.5.5 пункттагы «Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесенә» сүзләренә алмаштырырга;

10) 3.5.7 пункттагы «Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесенә» сүзләренә алмаштырырга;

11) 3.5.8 пункттагы «Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга, «Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары тарафыннан» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

12) 3 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 3.5.10 пункт белән тулыландырырга:

«3.5.10. Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге белгече җир участогын арендалау килешүенә үзгәрешләр кертү турындагы гаризаны һәм килешүне хокукларны теркәү органына җибәрә.

Срок – гариза бирүче тарафыннан имзаланган килешенү кире кайтарылган вакыттан башлап 5 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: килешенүне Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәү.»;

13) 4.2 пункттагы «муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары тарафыннан» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

14) 4.4 пункттагы «Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары» сүзләрен «Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

15) 5 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк белгечләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе.»;

16) 5.1 пунктта:

- беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына, эш

итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр тәртиптә – Башкарма комитетка, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре буенча – күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне оештыручы булып исәпләнгән гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) шикаять бирергә хокуклы.»

- түбәндәге эчтәлектәге 8, 9 пунктчалар белән тулыландырырга:

«8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату.»;

17) 5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазь йөрткечтә яки электрон төрдә бирелә.

Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.ru), күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.»;

18) 5.3. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк белгеченең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.»;

19) 5.4 пунктның 1 пунктчасын « муниципаль хезмәткәр» сүзләреннән соң «күпфункцияле үзәк, аның җитәкчесе һәм (яки) белгече,» сүзләре белән тулыландырырга;

20) 5.4 пунктның 3 пунктчасын «, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк белгечләре» сүзләре белән тулыландырырга;

21) 5.4 пунктның 4 пунктчасын «, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк белгечләре» сүзләре белән тулыландырырга;

22) 5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.»;

23) 5.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.10. Гариза бирүчеләр Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, шулай ук күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк белгечләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.»;

24) 2 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

25) кушымтаны (белешмә) әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.


Башкарма комитет
Җитәкчесе


Р.Ә. Абдуллин


Башкарма комитетның
2018 елның 6 сентябрендәге
4987 нче карарына
1 нче кушымта

Җир участогын арендалау
килешүенә үзгәрешләр кертү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

## Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы




Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге белгече документларны ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша соратып алу кирәклеген билгели
Документлар ны соратып алырга кирәк
юк
әйе
Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге белгече запрос җибәрә
Мәгълүматлар бирү турында запрос
Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге белгече муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен Регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булуны тикшерә
Мәгълүмат бирүчеләрнең белгечләре запросларны эшкәртәләр һәм мәгълүматларны бирәләр яки мәгълүматлар булмау турында белдерү кәгазе җибәрәләр
Документлар (мәгълүматлар) яки документлар булмау турында белдерү кәгазе
Кире кагу өчен нигез
Юк
Бар
Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге белгече кире кагу турында хат әзерли
Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең бүлек башлыгына җибәрелгән кире кагу турында хат
Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге белгече килешенү проектын әзерли һәм килешенү өчен җир һәм мөлкәти мөнәсәбәләр идарәсенең бүлек башлыгына җибәрә
Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәләр идарәсенең бүлек башлыгына җибәрелгән килешенү проекты
Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәләр идарәсенең бүлек башлыгы карар проектын карап тикшерә, килешенә һәм җир һәм мөлкәти мөнәсәбәләр идарәсе башлыгына җибәрә
Килешенү өчен җир һәм мөлкәти мөнәсәбәләр идарәсе башлыгына җибәрелгән карар проекты
Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәләр идарәсе башлыгы карар проектын карап тикшерә:
1) кире кагу турындагы хатны имзалый һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә;
2) килешенү проектын килешенә һәм килешенү өчен аны Башкарма комитетның хокук идарәсенә (алга таба – Хокук идарәсе) җибәрә
Имзаланган һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән кире кагу турында хат яисә килешенгән һәм килешенү өчен Хокук идарәсенә җибәрелгән килешенү проекты
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече кире кагу турында хатны терки һәм аны гариза бирүчегә җибәрә
Теркәлгән һәм гариза бирүчегә җибәрелгән кире кагу турында хат


Хокук идарәсе:
1) килешенү проектын карап тикшерә, килешенә һәм аны Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә;
2) килешенү проектына кимчелекләр әзерли һәм әлеге кимчелекләрне төзәтү өчен җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге белгеченә җибәрә
Килешенгән һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибрелгән килешенү проекты
Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге белгече кимчелекләрне төзәтә һәм килешенү проектын алга таба килешенү өчен Хокук идарәсенә җибәрә
Башкарма комитет Җитәкчесе килешенү проектын имзалый һәм теркәү өчен аны җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге белгеченә җибәрә
Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан имзаланган теркәү өчен җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге белгеченә җибәрелгән килешенү проекты
Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге белгече килешенү проектын терки һәм теркәлгән килешенүне имза куйдырып, гариза бирүчегә бирә
Теркәлгән һәм гариза бирүчегә бирелгән килешенү
Гариза бирүче тарафыннан имзаланган һәм җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе белгеченә тапшырылган килешенү
Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге белгече, арендалау килешүенә өстәмә килешенүне теркәп, теркәү турында гаризаны хокукларны теркәү органына җибәрә
Арендалау килешүенә өстәмә килешенүне Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәү

Башкарма комитетның
2018 елның 6 сентябрендәге
4987 нче карарына
2 нче кушымта

Җир участогын арендалау
килешүенә үзгәрешләр кертү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
кушымта (белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы
һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның
реквизитлары

| Вазыйфа | Телефон | Электронный адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | kancel.chelny@tatar.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы | 30-55-54 | uzioip@yandex.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы урынбасары | 30-55-54 | uzioipIP@yandex.ru |
| Башкарма комитет җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең аренда мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлеге башлыгы | 30-55-54 | uzioip@yandex.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге белгече | 30-55-54 | uzioip@yandex.ru |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова